Татарстан Республикасы

Аксубай муниципаль районы

Иске Кыязлы авыл җирлеге башлыгы карары

№ 2 2020 елның 20 октябре

Аксубай муниципаль районы

Иске Кыязлы авыл җирлегенә кергән

Яңа Кыязлы авылында

гражданнар җыены үткәрү турында»

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында " 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Аксубай муниципаль районы «Иске Кыязлы авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 22 статьясы нигезендә

Карар бирәм:

1. 2020 елның 29 октябрендә 10 сәгать 00 минутта ТР, Аксубай районы, Яңа Кыязлы авылы, Чапаев урамы, 20 нче йорт адресы буенча урнашкан йорт янында Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Иске Кыязлы авыл җирлегенә кергән Яңа Кыязлы авылында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының беренче этабын уздырырга.

2. 2020 елның 12 ноябрендә 10 сәгать 00 минутта ТР, Аксубай районы, Яңа Кыязлы авылы, Иванов урамы, 4 нче йорт адресы буенча урнашкан йорт янында Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Иске Кыязлы авыл җирлегенә кергән Яңа Кыязлы авылында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының икенче этабын билгеләргә.

3. Халык җыенына чыгарыла торган түбәндәге мәсьәләне расларга:

Сез 2020 елда Аксубай муниципаль районы Иске Кыязлы авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән, I төркем инвалидлар, Бөек Ватан сугышы ветераннары һәм көндезге формада белем алучы студентлардан тыш, 400 сум күләмендә үзара салым кертүегез

һәм акчаларны җирле әһәмияттәге түбәндәге эшләрне хәл итүгә юнәлдерү белән килешәсезме?

1.Торак пункт чикләрендә җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына карата юл эшчәнлеге:

- Яңа Кыязлы авылы урамнарын төзекләндерү (грунт күтәрү, вак таш салу, вак таш алу, торбалар алу).

« ӘЙЕ» “ЮК"

5. Карарны Аксубай муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга: http://aksubayevo.tatarstan.ru һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында бастырып чыгарырга: http://pravo.tatarstan.ru.

Иске Кыязлы авыл җирлеге

Башкарма комитеты җитәкчесе Г.Г.Дәүләтшин